**Татар телен укытуның нәтиҗәлелеген күтәрүдә**

**интерактив технологияләр**

Мәгариф министрлыгы да, ата-аналар да, җәмәгатьчелек тә балаларның татар телен  яхшы белүен таләп итәләр. Ә нинди юллар белән моңа ирешергә? Рус мәктәбендә укытучы буларак бу сорау мине уйланырга мәҗбүр итә. Укучыларда предметка кызыксыну уяту, актив, иҗади фикерләүче шәхес тәрбияләү кебек  максатларга ирешү өчен дәресләрдә интерактив технологияләр кулланмыйча мөмкин түгел. Икенче буын ФДБС буенча да укучыларны төрле эшкә җәлеп итү аша аларның фикерләвен, сөйләмен, рухи үсешен тәэмин итү бурычы билгеләнде. Шуннан чыгып, мин  "Татар телен укытуның нәтиҗәлелеген күтәрүдәинтерактив технологияләр"  дигән методик тема буенча эшлим.

Нәрсә соң ул интерактив укыту? Интерактив – inter (үзара), act (хезмәттәшлек итү). Интерактив метод белән укытканда укытучы-укучы-укучы арасында өзлексез бәйләнеш бара, барлык укучылар үзара  актив аралаша, бергә эш итә. Укучы уку-укыту процесыннан читтә кала алмый, аның активлыгы укытучы активлыгыннан күпкә югарырак та әле. Укытучы процесс белән җитәкчелек итә, юнәлеш бирә.

Нинди нәтиҗәләргә китерә соң интерактив технологияләр куллану?

1)укучыда өйрәнелә торган фәнгә карата кызыксыну уята;

2) укучының танып белү активлыгын арттыра;

3) иҗади мөмкинлекләрен тулырак ача;

4) инициативасын үстерә;

5) укучылар белемне үзләре табарга өйрәнә.

*)*Интерактив технологияләр бик күп төрле. Мин үзем дәресләрдә уен технологиясе, проектлар, рольле уеннар, браун хәрәкәте, интерактив тренажерлар, карусель, синквейн, попс-формула кебек төрләрен кулланам.

Эш тәҗрибәсеннән чыгып уен технологиясен рус телле балаларны татарча аралашырга өйрәтүдә иң нәтиҗәлесе дип саныйм.Мин дәресләрне төрле уеннар кулланып үткәрәм. Укучы тиешле булган лексик һәм грамматик материалны уйнау процессында үзләштерә. Сөйләм материалын истә калдыру өчен - сөйләм структураларын кабат-кабат тыңлыйбыз, ә ныгыту өчен даими кабатлап торабыз. Мәсәлән, "Бу сезнең сыйныфыгызмы?" "Әйе, бу безнең сыйныфыбыз. Безнең сыйныфыбызга рәхим ит!" - дигән катлаулы структураны рус телле 1нче сыйныф укучылары 5-6 нчы дәрестә бер авырлыксыз әйтә башлый. Балалар дәрескә тел, грамматика өйрәнергә дип түгел, укытучыдан ишеткәнне уртак уенда кулланырга килә.

Күнегүләрнең мавыктыргыч, балалар өчен кызыклы һәм бигрәк тә сөйләмгә ихтыяҗ тудырырга сәләтле булганарын сайлыйм.Төркемнәрдә эш, рольле уеннар аралашуга өйрәтүдә бик уңышлы юнәлеш булып тора.

Дәрестә татарча гына сөйләшү, бик күп төрле күрсәтмәлелек куллану да сөйләмне үстерүдә бик нәтиҗәле чара. Мәсәлән, икеяклы баскыч уенын барлык сыйныфларда да кулланып була. 1 нче сыйныфта хайваннар, яшелчә, җиләк – җимешләрне чагыштырсак, югарырак сыйныфта биремнәр катлаулана. Әдәбият дәресендә геройларны чагыштырып, эчтәлекне белүләрен тикшереп була. Ә беряклы баскыч уенында укучы бирелгән темага 1 яки ярты минут эчендә җөмләләр әйтергә тиеш. Шундый уеннар кулланганда, балалар кызыксынып, мавыгып эшлиләр, арымыйлар

Уеннарны башлангыч сыйныфлар гына түгел, өлкән сыйныф укучылары да яратып уйный. Шулай ук татар төркемнәрендә дә уеннар кулланам

Бүгенге көндә укучыларның функциональ грамоталылыгы – белем бирү сыйфатының мөһим күрсәткече булып тора. Дәрестә өйрәнелгән материалны практикада да кулланып карау - балалар өчен бик файдалы. Бергәләп урамда, музейда, экскурсиядә татарча сораулар бирү, социаль челтәрләрдә татарча аралашу, кибеттә нәрсәдер сатып алу предметны өйрәнүне тагын да кызыклырак итә. Укучылар татар телен дәрестә генә түгел, тормышта да куллана алулары белән бик тә горурлана, тагын да күбрәк беләселәре килә.

2022 ел Татарстанда Цифрлаштыру елы дип игълан ителде. Бу безнең алдыбызга яңа таләпләр, яңа бурычлар куя һәм безгә дә яңа информацион технологияләрне үзләштерүне дәвам итмичә мөмкин түгел. Шуларның берсе - нигезендә геймефекация методы яткан **интерактив тренажерлар** *(8 слайд).* Мин аларны дистанцион уку вакытында куллана башлаган идем. Укучыларга эш төре бик ошады, шуңа күрә хәзер ул биремнәрне интерактив тактада эшлибез. Барлык балалар да компьютер уеннары уйный һәм алар аша татар телен дә өйрәнеп булуы балалар өчен бик кызыклы.

Хәзерге вакытта бик актуаль **интерактив эш төре - Куар код аша биремнәр** бирү. Ул биремнәрне *LearningApps.org* программасында үзем төзим: кроссвордлар, диалоглар, шулай ук аудио-видео биремнәр ясыйм. Дәрес өчен кирәкле видеоны ютубтан алып куеп, шуңа сораулар да төзеп була. Шушы программа белән күнегүне эшләп бетергәч, ссылка һәм куар код чыга. Куар кодны тактага беркетеп куям һәм, гадәттә, өстәмә эш алырга теләгән укучыларга бирәм. Өй эше итеп бирелсә, *Классрум* аша җавапларны тикшерәм.

Шәхси сайтымда укучылар өчен дә, укытучылар өчен дә, ата-аналар өчен дә материал бар.

Социаль челтәрләр дә укучылар арасында популяр. Мин дә инстаграмм битен актив алып барырга тырышам. Бик күп укучыларым һәм ата-аналар миңа язылган, һәм алар минем татарча язылган постларны, сторисларны укып баралар, аңламаган җирен килеп сорыйлар, татарча комментарийлар язалар. Киләчәктә планнар –укучылар белән татарча дәрестә кулланган уеннарны кертеп тик-ток төшерү.

2018 нче елдан балалар өчен Шаян ТВ каналы эшли башлады. 2021 елда алар Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясебелән берлектә Шаян әлифба проекты әзерләделәр. Мин дә билгеле шәхесләребез Р.Вәлиев, Ә.Хуҗиәхмәтов белән берлектә шул проектның эксперт советы әгъзасы булып, ел дәвамында үз теләк –тәкъдимнәремне әйтеп бардым. Татар әлифбасын өйрәтә торган 39 цикл әзерләнде. Быелгы 1 сыйныф укучылары белән хәрефләрне Шаян Әлифба белән өйрәндек. Нәтиҗәсе бик яхшы булды, чөнки балалар шушы кыска гына җырлар аша 156 (һәр авазга 4әр сүз) сүзне истә калдыра алалар, авазларны дөрес әйтәләр.

Татар телен өйрәнү дәрес кысаларында гына түгел, дәрестән соң эшчәнлектә дә дәвам итә. Кызыклы эш формаларының берсе - укыган текстларны сәхнәләштерү. Башлангыч сыйныфларда халык әкиятләрен, А.Алиш, Г.Тукай әсәрләрен, югары сыйныфларда Т.Миңнуллинның "Әниләр һәм бәбиләр", К.Тинчуринның "Сүнгән йодызлар" һәм башка әсәрләрен сәхнәләштереп, сыйныфташларына, укытучыларга, ата-аналарга күрсәткәндә, балалар үзләренең татарча чыгыш ясый алулары белән чын күңелдән горурланалар.

Уку-укыту процессында ата-аналар белән дөрес эш алып бару да зур әһәмияткә ия. Алар белән дә тыгыз элемтәдә булып, дәресләргә чакыру, спектакльләр, концертлар күрсәтү, бергә төрле чаралар үткәрү татар теленә кызыксыну, мәхәббәт уята. Балаларының дәресләргә яратып йөрүләренә, татарча иркен сөйләшүләренә, дәрестә барысын да аңлауларына кайсы ата-ана каршы булсын!? Гомумән, укучының һәрбер уңышын әти-әнисе белергә тиеш дип уйлыйм мин. Ата-аналардан килгән хатлардан берничә җөмлә генә китерәсем килә: "Настолько живо и интересно проходитурок, ни одногослова по-русски не произносится". “Нас дети учат петь и разговаривать по-татарски. Как жаль, что нас не обучали так же!”

Дәресләрдә интерактив технологияләр куллану укыту сыйфатын күтәрергә, иҗадилыкны, укучыларның үзаллы эшләү сәләтен үстерергә,

креатив фикер йөртергә ярдәм итте дип саныйм. Бу сүзләремне уку сыйфатының күрсәткече һәм төрле конкурс-олимпиадаларда яулаган уңышларыбыз дәлилләп тора. Мәсәлән, 2018/19 уку елында мин укыткан рус төркемнәрендә уку сыйфаты 72% булса, 2019/20 уку елында – 79%, 2020/21 уку елында 84% тәшкил итте. Алдагы елларда олимпиадаларда күбрәк татар төркемендә укучы балаларым катнашса, хәзер рус төркемендә белем алучы укучыларым катнашып призлы урыннар ала. Мәсәлән, 2018/19 уку елында рус телле укучыларның татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль турында укучыларым 2, республика турында 1 призлы урын, 2019/20 уку елында муниципаль турда - 3, республикада - 1, 2020/21 уку елында муниципаль турда 4, республикада 2 призлы урын алды. Быелгы уку елында муниципаль турда 1 укучым җиңүче, 3 укучым призер булды. Халыкара, Бөтенрәсәй, республика күләмендәге конкурс-конференцияләрдә дә җиңүләребез елдан-ел арта.

Хезмәттәшләрем белән уртаклашырлык эш нәтиҗәләрем дә шактый җыелган. Тәҗрибәм белән шәһәр, республика, региональ, халыкара семинарларда, вебинарларда уртаклашам. Тьютор буларак, республика укытучылары өчен онлайн-дәресләр, мастер-класслар үткәрәм, Татарстанның Мәгарифне үстерү инситуты сайтына куяр өчен видео-дәресләр төшерәм. "Мәгариф", "Гаилә һәм мәктәп", "Татарстан" журналларында, "Ватаным Татарстан", "Шәһри Казан" газите битләрендә, "Казанский образовательный портал"да, Казан Федераль университетында чыккан фәнни җыентыкларда мәкаләләрем даими рәвештә басылып тора. Интерактив методлар кертеп төзелгән дәрес эшкәртмәләреннән торган һәм "Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерү алымнары" исемле методик әсбаплар өстендә эшлим.

V Бөтенрәсәй татар теле укытучылары съездында татар теле укытучылары исеменнән мөрәҗәгать белән, Алабугада мәгариф хезмәткәрләренең ТР президенты катнашлыгында үткән август киңәшмәсендә «Заман укытучысы–заман укучысына» докладлы белән, Грант алучы укытучыларның Мәгариф министры катнашлыгында үткән пленар утырышында барлык грант алучылар исеменнән чыгыш ясадым.

ТНВ, Шаян ТВ, Татарстан телеканалы тапшыруларына тәҗрибә уртаклашырга барам.

Шулай итеп, яңа мәгълүмати технологияләр белән танышу һәм дәрестә куллануны, иҗади үсешне тәэмин итүче методик әдәбиятны өйрәнү, эзләнү эшчәнлеген дәвам итү - киләчәккә перспективам. Укучыларны кызыксындырырлык юллар, алымнар, чаралар эзләү, һичшиксез, үзен аклый.